**Җәй-табигать түрәсе**

1. Көлә-көлә җәй йөгерә
Күккә тигән түбәсе!
Чәчәкле хәтфә күлмәктән,
Җәй-табигать түрәсе!

Кушымта: Кояш кыздырып ярата,
Иркәли нурларында.
Алма,җиләк,карлыганнар
Күчтәнәч кулларында.

2. Чишмә җырлый,кошлар сайрый,
Таллар суны үбәләр.
Күгәрченнәр парлап оча,
Гөрләп тора түбәләр.

Кушымта: Басу,кырлар уянганнар,
Яшелгә буянганнар.
Ләйсән яңгыр күкрәп уза,
Үләннәр куанганнар.

3. Сылу кыздай,ак каенны
Җил малае тирбәтә.
Су буйлары Сабантуйдай-
Коенмасаң тирләтә.

Кушымта: Ефәк тасма күбәләкләр
Күңелгә килеп куна.
Матур чаклар мәңге килми
Җәйләрдә кунак кына

Җәй йөгерә толымнарын
Гөлләрдән үрә-үрә.
Яшәргә язсын гомерне
Шатлыкка төрә-төрә!